СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.03.2021 г. Заинск № 32

**«Зәй муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез милекне милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартлары турында» 2020 елны 03 июнендәге 527 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карары белән расланган Зәй муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез милекне милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартларына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Зәй муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез милекне милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 03 июнендәге 527 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карары белән расланган Зәй муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез милекне милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Арендатор икътисадый эшчәнлекнең төп яки өстәмә төрләре буенча, алар турында юридик затларның бердәм дәүләт реестрында яисә хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә булган мәгълүматлар буенча билгеләнә.»;

3 пунктта:

беренче абзацта «2020 елның 1 октябренә кадәр» сүзләрен «2021 елның 1 октябренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

"б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) кичектерү тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә бирелә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының www.zainsk.tatar.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (PRAVO.TATARSTAN.RU) порталында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, икътисадый үсеш һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**